


**Сафиуллина, Рузия**
**Егерме еллык очыш / Р. Сафиуллина // Идел. – 2020. – № 10 (373). – С. 6-11: фото.**

Быел яшь шагыйрь, прозаик, драматургларның «Иделем акчарлагы» иҗади конкурсы үткәрелә башлауга егерме ел тула.

1990 еллар азагы – 2000 еллар башында «Иделем акчарлагы» яшь язучылар өчен бердәнбер иҗади бәйге иде. Гомумән, каләм тибрәткән яшьләргә һөнәрмәнд әдипләрнең дә, әдәбият сөючеләрнең дә игътибарын юнәлткән бердәнбер чара булды әле ул баштарак.

Егерме ел дәвамында әлеге конкурс аша ике меңләп кеше узды. Шигърияттә һәм прозада Гран-при яулаган лауреатлар гына да егермедән артык! Егерме ел дәвамында нлеге әдәби бәйгедә Татарстанның барча районнарыннан гына тугел, ә Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Пермь крае һәм Томск, Самара, Оренбург өлкәләреннән катнашучылар булды.

1999 елда старт алган шушы проект 20 ел эчендә шактый үзгәрде, заманчалаштырылды. Хәзер инде номинацияләр саны дүрткә җитте: поэзия, проза, драматургия, балалар әдәбияты. Жюри тарафыннан гадел бәя бирелсен өчен барлык катнашучыларның исемнәре анонимлаштырыла, аларга махсус код бирелә. Ел саен бәйгедә катнашырга теләүчеләр арта, чөнки «Иделем акчарлагы» чын-чынлап беренче очышка әзерли торган конкурс булып кала бирә.

Әлеге бәйгенең гран-при ияләре кем булган? «Иделем акчарлагы» конкурсының башлап җибәрүчеләре, оештыручылары кем булган? «Иделем акчарлагы» дигән иҗат мәктәбе аша үтеп, чыныгу алып, зур дөньяга чыккан язучылар арасында кемнәр бар? **Әлеге сорауларга җавапны Рузия Сафиуллинаның «Егерме еллык очыш» дигән мәкаләсендә укый аласыз.**